
Бәзәкәнең истәлекле урыннары
Презентация мәктәп укучылары, югары уку йорты студентлары игътибарына тәкъдим ителә.
Презентацияне Ф.З.Бәшәрова әзерләде


Татарстан Республикасында бай тарихлы карт авылларның берсе булган Бәзәкә Чулман елгасының уң ягында урнашкан. Элек авыл елгага 7 км чамасы ераклыкта булган. Ә Чулман белән Бәзәкә арасында киң болыннар, әрәмәлек, матур күлләр яткан. Түбән Кама сусаклагычы төзелгәч алар барысы да су астында калганнар. Көнбатышта авылдан 2-3 км читтә Сәйтәк авылы, 10 км ераклыкта Менделеевск шәһәре урнашкан. Төньякта авылның басу-кырлары, Тукмаклы ята. 5 км тирәсе ераклыкта Псәй авылы, көнчыгышка таба 7 км читтә Турай авылы урнашкан. Көнчыгышта колхоз кырлары, Умарталык, әрәмәлек күренеп торалар. Авылны икегә бүлеп таллар, бөрлегәннәр белән уратып алган инеш ага.

**Бәзәкә авылы урыны**
**(Бизякинское селище)**



**Авылдан көнчыгыш якта Чулман елгасына очлаеп кергән коры җирдә, су баса торган болыннан 15м биеклектә урнашкан. Бу мәйданда археологлар тарафыннан борынгы ананьино чорына карый торган keramиканың 18 төрле бизәкле фрагменты табылган.**

**Бәзәкә борынгы каберлеге**
**(Бизякинский могильник)**



**"Селище" янында урнашкан. Безнең гасырның III-IV гасырларына карый торган мәет калдыклары табылган: скелет, баш сөяге, балчыктан ясалган савыт. Каберлек 1994 елның2 июнендә ачылган**

## Әүлия каберлеге

Бу кабер авылның Тау башы дип аталган өлешендә урнашкан. Әүлия турында берничә юрама яши. Шуларның берсе буенча, авылның бер фәкыйрь гаиләсендә ике игезәк кыз үлгән һәм аларны менә шушы урынга күмгәннәр. Гөнаһсыз балалар, бигрәк тә аларның игезәк булуы монда зур роль уйнагандыр. Элек авыл әбиләре чистарынып, изге уйлар белән догалар укып, кабер янына килеп черем итеп алганнар. Черем иткән арада бу игезәкләр күзгә чалынып киткәлиләр, аларның кулында бер чүмеч су, бер кашык бал, икмәк телеме һ.б. күрәләр икән. Ә бу синең күпме гомерең калганын белдерә, имеш.



## Мәчет

Бәзәкә авылында Аллаһ йорты - мәчет 1989 елда "Кама" колхозы идарәсе һәм авылдашлар хисабына төзелә. Бүгенге көндә авыл өстендә азан тавышы яңгырый, мәчеттә дини бәйрәмнәр үткәрелә, укулар алып барыла.



## Шагыйрь М.Гыймазетдинов үскән йортта мемориаль такта

Үзәк урамның 78-нче йортында шагыйрь-патриот, «Яшәү мәгънәсе", "Язлардан алалмыйм күземне", "Син мине белмисең" шигырьләр җыентыгы авторы Марсель Гыймазетдинов туган. Мемориаль такта аның 50 яшьлек юбилее көнендә урнаштырылган.



## Иске колхоз идарәсе бинасы

Бу бина Сталин исемендәге колхоз заманында җиткерелгән. Бәзәкәгә утызменчеләрнең берсе - колхоз рәисе булып Б.В.Әхмәров килгәч бина киңәйтелгән. Бина колхоз төзелешенең авыр, ләкин искиткеч романтик еллары, Коммунистлар партиясе оешмасы, колхоз җитәкчеләре, белгечләре турында хатирәләр саклый.





"Кама" колхозының идарә йорты. 1980 ел.

## Мәдәният йорты




**Мәктәп артында урнашкан мәдәният йорты – күрше-тирә авыллар арасында узган гасырның 60-елларында беренче булып җиткерелгән мәдәни үзәк. 2016 елда бинага капиталь ремонт үткәрелде.**

## Мәктәп



**Мәктәп узган гасырның 60- елларында авыл төзүчеләре җиткергән архитектура истәлеге. 70- еллар башында мәктәпкә өстәмә бина төзелә. Мәктәптә аерым фәннәр буенча кабинетлар системасында уку-укыту бүлмәләре, зур спортзал, китапханә, балалар оешмасы бүлмәсе, укытучылар бүлмәсе бар.**

## Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл

1995 елда Бөек Җиңүнең 50-еллыгы уңаеннан авыл җирлеге үзидарәсе бакчасында ачылган. Һәйкәлгә сугыш кырларында ятып калган авылдашларыбыз исем-фамилияләре язылган. Бүгенге көнгә Бәзәкә авылыннан фронтка 779 кеше киткәнлеге билгеле. Шуларның якынча яртысы яу кырында һәлак булган.



## Тау башы мәктәбе урыны

Бу мәктәп Олы чишмә өстеннән менеп тау башында 1926 елда салынган булган. Авылдан ерак салынуның сәбәбе – янгыннан саклану һәм дин әһелләренең ризасызлыгына каршы килмәү. Агачтан җиткерелгән бу мәктәп яңасы төзелгәч сүтелгән.





Хәзерге вакытта бу урында агачлар гына үсә һәм балачагы шунда үткән авылдашларга бала-чага тавышлары белән тулы булган мәктәп ишек алдын һәм бакчаларын искә төшереп тора.

## Тукмаклы

Дистәләгән, хәтта 100 еллар элек, Сарсаз һәм Псәй авылларына бара торган туры юл куе урман белән капланган булган, шул юлда бер тирән чокыр да булган. Ике авыл арасында кешеләр йөреп торган. Ә бу чокыр тирәсендәге урманда качкыннар качып ятканнар. Алар юлдан үткән һәркемне тукмаклап әйберләрен алып кала торган булганнар.Шуңа күрә бу урынны "Тукмаклы" дип атап калдырганнар.



## Кызлар чокыры

Явыз Иван Казан ханлыгын алганнан соң татар халкын чукындыру өчен коралланган "карательный" отрядлар җибәргәннәр. Безнең бу тирәдә Сәйтәк, Бигәш дигән авыл татарларын чукындырганнар. Бәзәкә кешеләре авылдан 3 км ераклыктагы чокырларда качып ятканнар. Хатын-кызларны яшереп, ир-атлар еш кына авылга кайтып килгәли торган булганнар. Хатын-кызлар шушы чокырларда киндер сукканнар, мал-туар асраганнар. Бик озак торганнан соң гына кире авылга кайтканнар. Шул вакытлардан соң бу чокырлар Кызлар чокыры дип йөртелә башлаган.



## Баллы чишмә

Баллы чишмә авылның югары оч дип аталган өлешендә чыга, Бәзәкәй елгасына коя. Суы аеруча тәмле, йомшак булганга халык аңа Баллы чишмә дип исем куя. Бәзәкәнең иң уңган киленнәре, иң җитез,тырыш апалары вакытларын кызганмыйча һәрвакыт шушы чишмәгә суга йөргәннәр. Шигъри җанлы авылдашларыбыз М.Гыймадиев, Ф.Шакирова аңа багышлап шигырьләр дә язганнар.



## Олы чишмә



...Күптән түгел шул чишмәгә килдем:
Таш-кирпечтән чишмә киенгән.
Тирә-ягы яшел рәшәткәле,
Тал-тирәкләр аңар иелгән.
Йөрәк тибәмени!
Салкын суы
Бәреп тора ап-ак ташыннан.
Кем төзәткән? —
Шуңа рәхмәт әйттем,
Түбәтәем салып башымнан.
Авылымның чылтыр чишмәсе бар!
Көч-хәл өсти эчсәң сулары.
Шул чишмәдә очрашадыр кебек
Кешеләрнең гомер юллары.

Олы чишмә Баллы чишмәдән 200м түбәндәрәк ургып чыга,суы мул, тешләрне камаштырырлык салкын. Авыл халкының күп өлеше шушы чишмәгә суга йөри. Элек авылның бер урамы шул чишмәгә кадәр сузылган булган. Түбән Кама ГЭСы төзелә башлагач су күтәрелү көтелгәнгә күрә ул йортларны авылның югары өлешенә күчергәннәр. Шагыйрь М.Гыймазетдиновның шул чишмәгә багышланган шигыре дә бар.

## Татлы су чишмәсе

Авылыбызнын Кама елгасына якын ягында, Тубән оч белән Тау башы яки Шанхай дип аталган өлешләрен урталай бүлеп торган үзәнлектә салмак кына чишмә ага. Иң беренче булып аны күреп алган, чистартып юл ачып җибәргән кеше Зиннәтуллин Хәмәт бабай хөрмәтенә халык аны баштагы елларда «Хәмәт чишмәсе» дип йортте. Чишмә җир куеныннан ашыкмый гына агып чыга да салмак көйгә челтерәп Камага коючы Бәзәкәй елгасына кушыла. Бу чишмәгә суга күбесенчә Тубән очта яшәүчеләр һәм Тау башы халкы йөри. Җәйләрен халык чишмә буенда үскән каен һәм җир җиләге, бөрлегән белән сыйлана, табигать матурлыгы белән хозурлана.



НГДУ "Прикамнефть" чишмәне төзекләндергәннән соң "Татлы су" дип исем бирде.



Файдаланылган материал:
С.Таҗиев. "Туган авылыбыз Бәзәкә
кайда да безнең йөрәктә"
2020 ел